Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 21 (697) 14 ноябрь 2019 ел (1441, Рабигуль-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

Мәүлид мөбарәк булсын!

Рабигуль-әүвәл аеның 12нче көнен каршылап, Болгарда Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көненә багышланган традицион республикакүләм Мәүлид ән-Нәби кичәсе узды. Әлеге уңайдан оештырылган тантаналы чарага Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте дин кардәшләрен инде җиденче тапкыр җыйды. Бирегә голәмәләр, мөхтәсибләр, имамнар, ислам белем бирү йортлары мөгаллимнәре, шәкертләр, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре, Россия төбәкләренең мөселман дин әһелләре килде. Иң башта ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән һәм күптән түгел Мәскәүдә Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге мәйданчыгында беренче тапкыр җәмәгатьчелеккә рәсми рәвештә тәкъдим ителгән «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасының презентациясе булды. Республикакүләм Мәүлид ән-Нәби кичәсенең төп чаралары ахшам намазы белән башланып китте. Аннары бәйрәм залында Коръән уку һәм дога кылу белән чара рәсми рәвештә ачылды.

Иҗади чыгышлар сәламләүләр һәм котлаулар белән үрелеп барды. Дин кардәшләргә төп мөрәҗәгать белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады: “Хәдисләрдән билгеле булганча, пәйгамбәребез (с.г.в.) дүшәмбе саен ураза тоткан. Ни өчен дигән сорауга ул: «Бу минем туган көнем», – дип җавап биргән. Димәк, Рәсүлебез атна саен үзенең дөньяга килгән көнен ассызыклап, билгеләп уза торган булган. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: «(Рәсүлем!) Әйт: “Аллаһның фазылы (булган Коръән Кәрим) белән һәм Аның гына рәхмәте (булган Пәйгамбәре, Ислам һәм сөннәт) белән (бәхетле булсыннар), шуңа гына шатлансыннар. Ул (илаһи фазыл һәм рәхмәт) алар туплаганнардан яхшырак». («Юныс» сүрәсе, 58 нче аять). Ягъни фазыйләтләргә, пәйгамбәрләргә шатлану – ул безнең бурыч. Ә рәхмәтләр арасында иң зурысы – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) дөньяга килүе. Бу хакта Кәлам Шәрифтә болай диелә (мәгънәсе): «(Рәсүлем!) Без сине (җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп,) бөтен галәмнәр

өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек» («Әл-Әнбия» сүрәсе, 107-нче аять). Пәйгамбәребез (с.г.в.) булмаса, Коръәнне дә, Сөннәтне дә белмәс идек”.

Рабигуль-әүвәл ае – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган ай. «Мәүлид» сүзе гарәпчәдән «туу», «Мәүлид ән-Нәби» Аллаһ Илчесенең (с.г.в.) дөньяга килүен аңлата. Татарстан мөселманнары өчен мәчетләрдә, пәйгамбәрнең (с.г.в.) дөньяга килүенә ихлас күңелдән шатлануны белдереп, ай дәвамында төрле чаралар үткәрелә. Алар Аллаһ Рәсүленең (с.г.в.) тормышын өйрәнүне, аңа күпләп салаватлар әйтүне, Коръән аятьләрен уку, догалар кылу, вәгазьләр сөйләүне үз эченә ала. Мәүлид мәҗлесләре Пәйгамбәребез (с.г.в.) узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен искә төшерүне, аның күркәм әхлакый үрнәген өлге итеп алуны, рухыбызны тәрбияләү һәм ныгытуны максат итеп куя.

(ТР МДН сайтыннан)

Чаллы яңалыклары

29 октябрьдән башлап, бөтен дөнья мөселман халкы пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган мәүлид ае хөрмәтенә төрле чаралар, бәйгеләр һәм кичәләр үткәрә. 6 ноябрь көнне шәһәребезнең “Нур-Ихлас”, “Җәмигъ” һәм “Утыз Имәни” мәчетләрендә

дә әлеге айга багышланган мәҗлесләр булып үтте. “Нур-Ихлас” мәчетендә аны якшәмбе укулары укытучылары чәй өстәле янында үткәрде. Чараны укытучы апа вәгазьләр сөйләп, укучылар белән әңгәмә рәвешендә уздырды.

“Җәмигъ” мәчетендәге балалар өчен бәйге викторина рәвешендә үткәрелде. Аның барышында Илдар хәзрәт Зияров белән Мөхәммәд хәзрәт Мөхәммәтов балаларга пәйгамбәребез турында риваятьләр сөйләделәр һәм кызыклы сораулар бирделәр. Беренче булып җавап биргән балаларга

һәм аларның ата-аналарына бүләкләр тапшырылды. Шулай ук мәҗлес кунагы, шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин балаларга сәхабәләрнең пәйгамбәребезгә (с.г.в.) карата мәхәббәте турында сөйләде. Әлеге чара чәй өстәле янында тәмамланды.

“Утыз Имәни” мәчетендә пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тууына багышланган кичә ахшам намазыннан соң үткәрелде. Аның барышында Инсаф хәзрәт Сәубанов мәхәллә халкына Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлын сөйләде һәм мәүлид аена карата хөрмәтле булырга чакырды.

***

30 октябрь көнне Чаллы шәһәре имамнарының чираттан тыш җыелышы булды. Ул икенде намазыннан соң шәһәребез мөхтәсибәтендә үткәрелде. Фикерләшү темасы итеп пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган мәүлид аенда үткәреләчәк чаралар алынды. Мәҗлес барышында имамнар мәчетләрдә Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) белән бәйле вәгазь кичәләре һәм викториналар ясарга кирәк дигән уртак фикергә килделәр. Шулай ук Мәүлид ае хөрмәтенә үткәрелгән “Минем Пәйгамбәрем” дип аталган видео-роликлар һәм “Пәйгамбәребез Мөхәммәд шәҗәрәсе” конкурсларын уздыру вакытын да озайттылар. Конкурста катнашырга теләүчеләр ике бәйгегә дә 22 ноябрьгә хәтле үзләренең эшләрен muhtasibchelny@yandex.ru почтасына юллый алалар. Нәтиҗәләр 23-24 ноябрь көннәрендә ясалачак, ә җиңүчеләрне бүләкләү 25 ноябрь көнне булачак.

Конкурсларның тулы шартлары:

“Минем Пәйгамбәрем” дип аталган темага видео-роликлар буенча конкурс: Уздыру вакыты: 12 октябрьдән 22 ноябрьгә чаклы. Катнашучыларга таләпләр: Мөселман булу. Яшь арасы чикләнмәгән. Видео-материалга таләпләр: Татар телендә булу һәм әчтәлегенең темага туры килүе. Вакыты 5 минуттан артмаска тиеш. Җиңүчеләрне сайлау: 23-24 ноябрь. Сайлау вакытында беренче урында видео-роликның эчтәлеге торачак. Остальык һәм видео сыйфаты – икенче урында.Бүләкләү: 25 ноябрь. Призлар: 1 урын – 5000 сум, 2 урын – 3000 сум, 3 урын – 2000 сум. Бәйгедә катнашу өчен әзер видео-материалларны muhtasibchelny@yandex.ru почтасына җибәрү сорала. Шулай ук конкурста видеоязманы Instagram социаль челтәренә салып, @islamchally аккаунтын видео астына беркетеп тә катнашып була.

“Пәйгамбәребез Мөхәммәд шәҗәрәсе”: Кем иң төгәл, иң аңлаешлы, иң матур рәвештә ясый – шул җиңүче була. Эшләрне А4 яисә А3 форматындагы кәгазь битендә ясарга кирәк. Ф.И.О. һәм яшегезне дә языгыз. 22 ноябрьгә чаклы Чаллы 48/09 адресына (Чулман проспекты 108/5), “Нур-Ихлас” мәчетенә китереп җиткерү яисә muhtasibchelny@yandex.ru почтасыа юллау сорала. Катнашучыларга һәм җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылачак.

Нияз ГАЗИЗОВ.

Күркәм холык җәннәткә илтә

Ислам динебезнең нигезе булып тәүхид — бер Аллаһка гына ышану торса, аның икенче мөһим өлеше - гүзәл әхлак, күркәм холык. Аллаһ Раббыбызның безгә йөкләгән фарызлары, тыйган хәрамнары әхлакны төзәтү өчен. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) дә: «Мин изге холыкларны тәмам өйрәтү өчен җибәрелдем», — ди үзенең бер мөбарәк хәдисендә. Пәйгамбәрләрнең һәрберсе гүзәл әхлак өйрәтү нияте белән күндерелгән булсалар да, Расүлуллаһ (с.г.в.) исә шуны тәмам итеп өйрәтү һәм камиллеккә ирештерү өчен җибәрелгән. Димәк, иман китереп үзен мөселман дип санаучы һәркем әхлагын төзәтү өчен һәрдаим тырышырга тиеш.

Бер җирдә бик күркәм холыклы, бик әдәпле бер кеше яшәгән. Аннан: «Син бу сыйфатларга ничек итеп ирештең?» — дип сорагач: «Мин яшәвемнең нигезе итеп дүрт кагыйдәне алдым», — дип җавап биргән.

Беренче кагыйдә. «Аллаһ сөбехәнәһү үә хак Тәгалә тарафыннан кешегә билгеләнгән байлык артмый да, кимеми дә. Шуның өчен дә кемнәрнеңдер байлыгы, дәрәҗәсе минекеннән артык икән, алардан көнләшмим, нәрсәдер булдырам дип тырышып та барып чыкмый икән, йә каза килә икән, кайгырмыйм», — дигән.

Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхабәләргә: «Бүген сезнең яныгызга җәннәткә керәчәк бер кеше килә», — дип игълан иткән. Ә теге кеше килгәч, сәхабәләр аның артыннан күзәтеп йөри башлаганнар. Берничә көн күзәткәч, аның башкалардан артык гыйбадәт кылганын күрмәгәч, аптырап: «Синең кешеләрдән артык нинди сыйфатларың бар?» — дип сораганнар. Әлеге кеше әйткән: «Мин үз гомеремдә берәү турында да начар сүз сөйләмәдем һәм берәүдән дә көнләшмәдем». Нинди күркәм сүзләр. Кызганыч ки, күпвакыт кеше турында начар сүзләрне ул яман булган өчен түгел, ә ниндидер уңышка ирешүеннән көнләшеп сөйлиләр. Күпмедер тырышсаң, фарызларны да үтәп була, нәфелләрне дә. Әлеге кеше әйткәнне эшләргә кайсыбызның көче җитә? Әйдәгез, шуңа омтылыйк. Югыйсә, һәркайсыбыз белә бит: һәр әйткән сүз үзебезгә әйләнеп кайта, яхшымы ул, начармы ул. Һәркайсыбыз Аллаһ бүләк итеп биргән акыл белән фикерләсен иде: нинди сүзләр сөйләргә кирәк икән? Начарлыкны сөйләүче ул шуны таратучы да, үзенә начарлык теләүче дә булып тора. Аллаһ Раббыбыз Коръән Кәримдә (17 нче «Бәни Исраил» сүрәсе, 7 нче аять): «Әгәр яхшылык кылсагыз, үзегез өчен кылган буласыз, әгәр явызлык кылсагыз, янә үзегезгә яманлык булып кайтачак», — ди.

Имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре дәрес биргәндә, бер шәкерт кереп, «Хәзрәт, сезнең сәүдә малыгыз төялгән көймә баткан», — дип хәбәр биргән. (Имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре иң зур галим генә түгел, ә сәүдәгәр дә булган. Диннән кәсеп ясамасыннар дип, һөнәре, кәсебе булмаганнарны шәкерт итеп тә алмаган). Хәзрәт бераз гына кальбенә карап торган да: «Әлхәмдүлилләәәһ», — дип, дәресне дәвам иткән. Бераз вакыттан соң икенче берәү килеп: «Баткан көймә сезнеке булмаган, сезнеке яр кырыена килеп җитте», — дип хәбәр биргән. Хәзрәт янә бераз кальбенә карап торган да: «Әлхәмдүлилләәәһ», — дип дәресне дәвам иткән. Шәкертләр, дәрес беткәч: «Хәзрәт, сез ни өчен ике очракта да бертөрле җавап бирдегез?» — дип сорагач, «Мин беренче очракта кальбемдә бер кайгы күрмәдем, икенче очракта шатлык, дулкынлану күрмәдем, шуңа күрә: «Әлхәмдүлилләәәһ», — дидем», — дип җавап биргән. Байлык кешенең күңелендә түгел, кесәсендә булырга тиеш. Калеб иман өчен, аның урынын байлык алса, ул кеше дөньяда һәм ахирәттә бәхетсез була. Бу, әлбәттә, эшләмәскә, дөньядан ваз кичәргә дигәнне аңлатмый. Көчең, сәләтең бар икән, тырыш, кәсеп ит, өең дә, машинаң да, киемең дә яхшы булсын, әмма фарызларны үтәмичә, хәрамга кереп батарга тиеш түгелсең.

Әлбәттә, Аллаһ тәкъдирләгән байлык артмый да, кимеми дә, әмма Аллаһ шул байлыкны булдыруда кешене сәбәпче итеп куйган. Дөнья тормышында шул байлыкка хәләл юл белән дә, хәрам юл белән дә ирешеп була. Кайсы юл белән барсаң да, сиңа язган байлык синеке, берәүнеке дә сиңа керми, синеке дә башкага китми. Әмма хәрам мал сине дөньяда хурлыкка калдыра, сине җинаятьче ясый, ахирәттә тәмуг утынына кисәү итә.

Бер бай үләр алдыннан: «Минем белән бер көн кабердә яткан кешегә ярты байлыгымны бирәм», — дип васыять әйткән. Ул бай үлгәч, берәүнең дә кабердә ятасы килми икән. Бер бик фәкыйрь йөк ташучы булган. Ул ризалашкан.

Кабергә сөаль фәрештәләре килгәч: «Бу бай беркая да китми, сорау алуны бу кешедән башлыйк», — дип сорау ала башлаганнар. Әлеге кешенең йөк ташый торган бер бавы бар икән. Аны каян алган, нинди акчага юнәлткән, нинди максатларда файдаланган? Бик озак тилмерткәннәр. Икенче көнне казып чыгаргач, әлеге йөк ташучы җан-фәрманга чаба икән. Кешеләр: «Әй, тукта, үзеңә тиешле өлешне ал», — дип туктатмакчы булганнар. Йөк ташучы: «Бер бау өчен күпме җавап тоттым, ул байлык өчен ничек җавап биреп бетермәк кирәк», — дип байлыктан баш тарткан.

Кыямәт көнендә һәркайсыбыз байлык турында ике төрле сорауга җавап тотачакбыз. Беренчесе — малларыңны нинди юллар белән таптың? Икенчесе — малыңны нинди җирләргә исраф иттең? Сәламәтлегең, сәләтең булып, Аллаһның рәхмәте белән байлыкка ия булгансың икән, кырыктан бере (2,5 проценты) синеке түгел, ә ятимнәр, мескеннәр, дин юлында тырышучылар өлеше. Аллаһ теләсә, сине бер мизгелдә байлыксыз калдыра ала, яисә үзеңне шул байлыктан файдалана алмый торган итәргә мөмкин.

Бер бай кеше Зәйнулла ишанга әйтә икән: «Хәзрәт, акча булса, бар да була бит, шуңа күрә байлык артыннан куып намазларымны да вакытында укый алмыйм», — дип. Зәйнулла ишан: «Әйе, байлык булса бар да була. Әйтик, базарга чыгып, җаның ни тели, шул ризыкны сатып ала аласың, әмма Аллаһ бирмәсә, аппетитны сатып ала алмыйсың. Бүген күпме кешеләргә ашаган саен начар була. Акчаң булса, яхшы урын-җир сатып ала аласың, әмма йокыны сатып ала алмыйсың. Бүген күпме кеше йокысызлыктан интегә. Акчаң бар икән, кыйммәтле дарулар ала аласың, яхшы табибләр янына барырга мөмкин. Тик Аллаһ теләмәсә, шифа таба алмыйсың. Акчаң булса, яхшы йорт ала аласың, әмма йорт эченә тынычлыкны сатып алып куярга һич мөмкин түгел. Акчаң бар икән, дусларың да күп була, әмма акчага аларның мәхәббәтен яулый алмыйсың. Акчаң булса, балаң ни сорый, шуны алып бирә аласың, әмма аңа тәүфыйк-һидаять сатып ала алмыйсың», — дип җавап кайтарган. Әйе, акчаң да булсын, әле санап киткәннәре дә булсын, дисәң, акча хәләл юл белән табылырга һәм тиешле зәкятләре биреп барылырга тиеш.

Бер кеше: «Сиңа язган ризык барыбер сиңа керә», — дигәнне сынап карамакчы була. Өенә кайта да: «Мин ашамыйм», — дип игълан итә. Хатыны ашарга үгетли. Хатынның үгетләвеннән туеп, авыл башына чыгып утыра. Хатыны, кызганып, янына ашъяулык белән ризык чыгарып куя. Бераздан ач юлбасарлар килеп чыга. Күрәләр, ризык тора. Берсе әйтә: «Агуланган ризыктыр бу», — дип. Сынап карамакчы булалар. Күрәләр, бер кеше утыра. «Аша», — диләр. Баш тарта. Шуннан ачулары чыгып, тешләрен сындырып, авызын каерып ачып, ризыкны йотарга мәҗбүр итәләр. Бераз көтеп торалар, әлеге кеше үлмәгәч, калган ризыкны ашап китәләр. «Насыйп ризык тешне сындырып та керә», — дигән сүз шуннан калган, имеш.

Икенче кагыйдә. Аллаһ каршында минем бурычларым бар, аны минем өчен берәү дә түли алмый, мин шул бурычларны түләү белән мәшгульмен.

Харун әр-Рәшид патша берәр галим белән очрашасы килүен әйткәч, аны бер галим янына алып барганнар. Күпмедер сөйләшеп утыргач, патша: «Бурычларың бармы?» — дип сораган. Уңай җавап алгач, әлеге галимнең бурычларын түләргә кушкан. Патшаны башка галим янына алып барганнар. Анда да шул ук хәл кабатланган. «Тагын берәр галим юкмы?» — дигәч, аны Фузайл ибн Ийяз янына алып барганнар. Патша аңардан да: «Бурычларың бармы?» — дип сораган. Фузайл ибн Ийяз: «Бурычларым бик күп, әмма, падишаһым, син аны түли алмыйсың», — дигән.

Харун әр-Рәшид патша бик аптырап: «Минем байлыгым күп, мин теләсә нинди бурычны түли алам», — дигәч, «Минем Аллаһ каршында бурычларым бар, аны минем өчен берәү дә, шул исәптән син дә түли алмыйсың», — дигән. «Мин кешеләр белән ике арадагы бурычны сорыйм», — дигәч: «Аллаһ биргән нигъмәтләргә шөкер итмичә, кыска гына гомерем өчен бурычка кереп мәшәкатьләнмәдем», — дип җавап кайтарган.

Падишаһ елап җибәргән һәм үзенә нәсыйхәт кылуны сораган. Фузайл ибн Ийяз: «Әй, падишаһым, Аллаһны таныган бер мизгел меңәр ел меңләгән кеше белән идарә итүдән хәерлерәк», — дигән. Чөнки кеше үз гомерендә Аллаһны танымаса, тәүбә кылып иман китермәсә, Аллаһ кушканнарны (5 вакыт намаз, ураза, зәкят, хаҗ) үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәмәсә, аның соңгы урыны җәһәннәм була. Бу дөньяда нинди генә дәрәҗәгә, байлыкка ирешсә дә, җәһәннәмнән котыла алмый.

Харун әр-Рәшид тагын нәсыйхәт әйтүен сораган. «Әгәр Аллаһның рәхмәтенә ирешәсең килсә, патшалыгыңдагы өлкәннәр әтиләрең кебек булсын, кечеләре — энеләрең, аларның балалары үз балаларың, дәүләтеңнең бар җире үз өең, анда яшәүче халыклар гаиләң кебек булсын. Әтиеңнең хәлен бел, туганнарыңны хөрмәт ит, балаларыңа мәрхәмәт күрсәт, өеңнең тынычлыгын кайгырт», — дип нәсыйхәт кылган Фузайл. «Уттан котыласың килсә, үз вазыйфаңны Гомәр радый Аллаһү гәнһемнән дә яхшырак үтәргә тырыш», — дигән.

Патшаның күңеле булып, 1000 динар бирергә кушкан. Фузайл: «Падишаһым, берни дә аңламадыңмыни, мин сиңа нәсыйхәт биреп, котылу юлын күрсәтмәкче булам, ә син мине утка этәрәсең», — дигән. Икенче риваятьтә әйтелгәнчә: «Падишаһым, син акча турында уйлыйсыңмы?» - дип сораган. «Әйе», — дип җавап биргәч, «Аллаһ миңа нәфесемне җиңәргә ярдәм итте, нәфес минем колым булды, ә син һаман нәфес колы икәнсең, шулай булгач, син минем колымның колы буласың. Ничек итеп мин үз колымның колыннан нәрсәдер алыйм», — дигән. Харун әр Рәшид патша күз яшьләрен көчкә тыеп: «Әй, Фузайл, Фузайл — менә кем чын солтан», — дип иптәшләренә әйткән.

Аллаһ безне акыл белән зиннәтләгән һәм аны намаз белән тәрбия кылырга кушкан. Кем Аллаһ каршындагы шул бурычны үтәми, акылы тәрбиясез була. Берничә уку йорты бетерү, гыйльми дәрәҗәләр алу әле ул тәрбияле булу, дигән сүз түгел. Акылың тәрбияле икән, ул синең әгъзаларыңны гөнаһлы эшләрдән тыеп торырга тиеш.

Адәм баласында нәфес тә бар. Без нәфесне ураза белән тәрбия кылырга тиеш. Шулай тәрбия кылынмаганда, нәфес кешегә хуҗа була һәм аңа ияреп, кеше үз-үзенә золым сала. Шуның өчен дә Аллаһның безгә йөкләгән фарызлары — безнең Аллаһ каршындагы бурычларыбыз, аны безнең өчен башка беркем дә үти алмый, һәркайсыбыз дөньяда һәм ахирәттә бәхетле буласыбыз килсә, тизрәк - тәүбәгә килик һәм намус белән бурычларыбызны түли башлыйк.

Өченче кагыйдә. Минем бер дустым бар, мин аның белән очрашырга әзерләнәм. Ул дус «үлем» дип атала. Дөньяда ике генә хакыйкать бар. Аның берсе — Аллаһ Тәгалә, без аны танырга, тормышыбызны Ул кушканча көйләргә тиеш. Башка бар нәрсә дә вакытлыча һәм үтүчән. Акыллы кеше мәңгелек сәгадәтне вакытлы мавыгуларга сатмый. Икенче хакыйкать - үлем, аңа әзерләнергә кирәк.

Бер бик бай кеше, бик кәефләнеп, байлык хикмәтләренә хозурланып, горурланып диванда ята икән. Ишек шакыганнар. Усал гына итеп: «Кем анда?» — дип кычкыра икән. Ә тегеннән җавап: «Бу — мин, әҗәл булам», — ди икән. Тегесе кырыс кына: «Ну и что?» — дигән. Әҗәл тыныч кына: «Ну и все», — дигән, һәркем «Ну и все», - дигән вакытка әзер булырга тиеш.

Кайбер халыкларда олырак кешеләр чиста киемнәрен киенеп үлем көтеп ята. Әмма үлемгә әзер булу алай түгел. Үлем сине гомереңнең кайсы гына мизгелендә куып җитсә дә, эшләгән изгелекләрең гөнаһларыңнан күбрәк булсын. Дөньядан иман белән үтәрлек итеп яшә, бу инде «Аллаһ каршындагы бурычларны үтәп яшәү», — дигән сүз.

Колак салсаң, үкенмәссең

* *Балыкның ауга эләккәч акылы башына килә*

* *Иртәгә үкенерлек эшне бүген эшләмә*

* *Тауга менгәч сусавыңнан ни файда?*

* *Терсәкне бик тешләр идең дә, буй җитми*

* *Бер кичеккән эш илле елга кичегер*

* *Биш иртәгәдән бер бүген кыйбат*

* *Бүген эшләнәсе эшне иртәгә калдырма*

* *Һәр нәрсә үз вакытында яхшы икәнне әтәч тә белә*

* *Һәр кешенең үз нәфесенә җитсә көче,*
Дәрәҗәдән коры калмас андый кеше.

* *Үзен иркәләгәнне бер көн дөнья типкәләр*

* *Үзенә ышанган — йокыдан торып киткән,*
Әтәчкә ышанган ятып калган.
* *Үзеңә үзең каты тор,*
Чыгымчы атка йөгән ор!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Кем үлми, теләсә нәрсә эшләсен», — ди. Бүген күбебез яхшы дару, яхшы табиб эзләп гомерен үткәрә, акчасын түгә. Бу мәсьәләдә ярдәм итә алабыз, дип күпме кеше башкаларны алдап баеп ята. Үлемнән алып кала торган дару һәм табиб юк, булмаячак та. Яшәү табигый булган кебек, үлем дә табигый. Бернинди байлык, дәрәҗә дә аннан алып кала алмый.

Бер кеше үләр алдыннан балаларын чакырып китерә дә: "Балаларым, мин сезгә ике конверт калдырам, мин үлгәч тә беренчесен укыгыз, аннан авылның имамына барыгыз, имам янынннан кайткач икенчесен укырсыз", – ди. Әтиләре үлгәч, балалар беренче конвертны ачып укысалар, анда: "Гомерем буе аягым туңып интектем, аягыма оекбаш (носки) кидереп күмегез", – дип язылган. Балалары хәзрәткә барып васыятьне күрсәтәләр. Хәзрәт: "Шәригатькә каршы васыять үтәлми, кәфеннән артык бернәрсә дә рөхсәт итмим. Әгәр сүземә каршы төшсәгез, җеназа укымыйм", – ди. Балалары бик кайгырышып өйләренә кайталар һәм икенче конвертны ачалар. Анда: "Балаларым, күрдегезме, күпме байлык җыйдым, әмма үзем белән бер пар оекбаш та алып китә алмыйм", – дип язылган була.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Әй, адәм баласы, өең белән мактанма, актыккы өең кабер булыр, әй, адәм баласы, киемең белән горурланма, актыккы киемең кәфен булыр; әй, адәм баласы, утырып йөргән әйберләрең белән мактанма, актыккы барган нәрсәң кабык булыр, әй, адәм баласы, ашаган ризыгың белән мактанма, бер көн үзең башкаларга ризык булырсың», — дигән.

10 сумлык акча үлеп киткән, озатырга килүчеләр әз булган. Юганнар, кәфенләгәннәр, җеназа укып күмгәннәр. Агач чардуган, исемен язып такта куйганнар. Теге дөньяда кубарылса, иң бөек дәрәҗә — җәннәткә эләккән (җәннәт 8 дәрәҗәле).

100 сумлык үлгәч, озатырга килүче күбрәк булган. Юганнар, кәфенләгәннәр, җеназа укып күмгәннәр, агач чардуган, кечкенә генә таш куйганнар. Икенче дәрәҗә җәннәткә эләккән.

500 сумлык үлгән. Кеше байтак җыелган. Юганнар, кәфенләгәннәр, җеназа укып күмгәннәр. Тимер, чардуган, мәрмәр таш куйганнар. Күч-хәл белән җәннәткә эләккән.

1000 сумлык авырып киткән, ярты шәһәр халкы аякка баскан, табибләр чабышып хәлдән тайган, барыбер үлгән. Бик күп кеше җыелган. Мөфтине җеназа укырга чакырганнар. Бик әйбәт нотыклар сөйләп, аны да юып, кәфенләп озатканнар. Күгәрми торган тимердән чардуган, граниттан биек таш куйганнар. Җәннәткә керә алмаган. Узенең дәрәҗәле, ничек итеп озатканнарын әйтеп жалоба (шикаять) язган. Шикаятенә: «Син мәчеттә бик аз күрендең, күбрәк казино, ресторан тирәләрендә йөрдең, мәчет кассасында нигездә ун сумлыклар иде», — дип җавап биргәннәр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Кем үлә — ул йокысыннан уяна», — дигән. Димәк, бу дөнья төш кенә. Мондагы кыйммәтләр анда ярамый. Әлбәттә, соңгы юлга да матур итеп озатсыннар, әмма анда алып барырлык изге гамәлләрегез дә булсын. Бер галим: бу дөнья язгы кояш астындагы кар кебек, эреп юкка чыгачак. Ә изге гамәлләр кыйммәтле асылташлар кебек, торган саен бәһаләре арта, дигән. Газиз дин кардәшләрем, шул асылташларны күбрәк әзерлик. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дән сораганнар: «Әгәр берничә минуттан ахырзаман җитә, дисәләр, ни эшлик?» — дип. Ул: «Кулыңда бер үсенте бар икән, өлгерә алсаң, утыртып калырга тырыш, кыямәт көнендә сиңа файдасы тияр», — дип җавап кайтара. Димәк, һәркем гомеренең соңгы сулышына кадәр изгелек эшләп калырга тырышырга тиеш. «Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылса да, игелеген күрер, берәү тузан бөртеге кадәр генә гөнаһ кылса да, җәзасын күрер», — ди Аллаһ Раббыбыз Коръән-Кәримдә (99 нчы «Зилзилә» сүрәсе, 7, 8 нче аятьләр).

Дүртенче кагыйдә. Мин, иман китергән кеше буларак, Аллаһның һәрвакыт мине күреп торуын беләм, үлгәч, Аның каршына барып җавап бирәчәгемә ышанам. Шуңа күрә дә Аллаһ каршында йөзем кызарырлык эшләр эшләмәскә тырышам.

һәркем иман китергән икән, 7 нәрсәгә шикләнмичә ышанырга тиеш.

1. Аллаһның барлыгына, берлегенә.
2. Фәрештәләренә.
3. Китапларына.
4. Пәйгамбәрләренә.
5. Заман ахырына.
6. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһ Тәгаләдән булуга.
7. Үлгәннән соң терелүгә.

Кызганыч ки, күп кешеләр үлгәннән соң терелүгә бераз шикләнеп карыйлар. Әгәр кеше үлеп терелячәгенә, аннан соң җавап бирәчәгенә чын күңелдән ышанса, күп гөнаһлардан тыелырга үзендә көч табар иде. Коммунистик мораль да начар түгел иде, әмма ул кеше сүзенә һәм кеше күрү-күрмәвенә корылган иде. Кеше күзе күрмәсә, ничек хәл итсә дә ярый булып чыга. 1985 елда партиянең «Алкогольгә каршы көрәш» монополиясе башлангач та, уңышка ирешә алмады. Чөнки яшереп, кеше күрмәгәндә эчү гаеп саналмады. Ә бит Аллаһ бар һәм бар җир дә Аның күзәтүендә, Аның фәрештәләре безнең кылган гамәлләребезне генә түгел, уйлаган уйларыбызны да язып, бүгенгечә әйтсәк, видеога төшереп баралар.

Инде кыямәт көнендә җавап бирүне күз алдына китерик, һәркемгә үзе-турында төшерелгән видеотасма күрсәтелә. Син бер кеше янында ялагайланып, аны мактап торасың, ә уйларың киресенчә, шуны менә бергә карыйсың, шулвакыт йөзеңнең ничек кызарасын күз алдыңа китер.

Зөләйха Йосыф галәйһиссәлләмне зинага чакырганда, Йосыфка (г.с.) иманы шушы эштән тыелып калырга көч бирде. Йосыф (г. с.): «Мин Аллаһтан куркам», — дип төрмәдә утыруны зинадан өстен күрде. Аллаһ Раббыбыз шушы сынауны уңышлы үткәне өчен аңа патшалыкта дәрәҗә һәм пәйгамбәрлек бирде. Әгәр Йосыф (г.с): «Берәү дә күрми әле», - дип зинага ризалашса, күпмедер кәеф-сафа корып яшәгәч, бервакыт аны куып чыгарырлар иде дә, дөньяда хурлыкка калыр, ахирәттә урыны җәһәннәм булыр иде.

Бер бозык җитәкче үз өлкәсендә эшләүче хатынның өенә кереп: «Ишек-тәрәзәләреңне биклә, минем синең белән буласым килә», — дигәч, әлеге хатын: «Мин бикли алмый торган тәрәзә бар, аны нишләтәбез?» — дип әйткән. «Ул нинди тәрәзә?» — дигәч, «Аллаһ белән ике арадагы тәрәзә», — дип җавап кайтарган. Әлеге җитәкче кызарыныпчыгып китәргә мәҗбүр булган. Бәлки ул хатынга киләчәктә эшендә авырлыклар күрергә туры килер, әмма кыямәт көнендә Аллаһ хозурында йөзе ак булыр. Аллаһ Раббыбыз: «Әгәр берәү беркем күрмәгәндә, бер Миннән генә куркып, үзен бер хәрамнан тыйса, аның урыны җәннәттә булыр», — ди.

Аллаһ Раббыбыз хәрам дигән нәрсәләр безнең калебләребезне каралта, бездәге ихтыяр көчен бетерә, шуның белән дөньяда без нәфес колларына әйләнәбез һәм үзебезгә үзебез золымлык кылабыз. Эчүчелек, наркомания, җинаятьчелек барысы да шуның нәтиҗәсе.

Гади генә дүрт кагыйдә, ә аларда нинди зур мәгънә ята. Ислам диненчә яшәүнең ике төп кагыйдәсе бар. Беренчесе: кеше үз нәфесенә булышып, үзенә-үзе зыян китермәскә тиеш. Икенчесе: кеше үз-үзенең тотышы белән башкаларга зыян салмаска тиеш. Барчабызга да Аллаһ риза булырлык итеп яшәргә насыйп кылса иде.

Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,
Татарстанның баш казые.

ӘДӘБИ СҮЗ

Рифат СӘЛАХ

Җомга иртәсе

Әллә кая йөгерәсе килә,
Әллә кая килә китәсе.
Офыкларны янә нурлы итә
Бүген туган җомга иртәсе.
Әллә кая йөгерәсе килә,
Диңгезләрнең аргы ягына.
Әллә ниләр көтә бүген күңел,
Әллә кемне өзелеп сагына.
Җилләре дә күк гөмбәзен иңләп,
Кояш назын чәчә илемә.
Шәһәр гөрелтесе тына төсле
Күмелгәндә кошлар көенә.
Офыкларны янә нурлы итә,
Җырлы итә көннең балкышы —
Кояшның да бүген әйтерсең лә
Кыйблаларга атлап барышы.
Үз кыйблаңны тапсаң,
җан нурлана,
Әллә кая килә китәсе.
Гел күңелне җилкендереп торсын
Һәрбер яңа җомга иртәсе!

Кыямәт көненең галәмәтләре

(Дәвамы. Башы газетаның алдагы санында)

Булган һәм кабатланып торган галәмәтләр.

5. Малның, байлыкның күбәюе. Кыямәт көне алдыннан бай кешеләрнең саны бик нык артачак, шул сәбәпле зәкят-сәдака бирерлек кешеләрне, ягъни мохтаҗларны табу кыенлашыр. Хәдисләрнең берсендә бу хакта болай диелә: "Кешеләр исәпсез байлыкларга ия булмыйча, кыямәт көне килеп җитмәс. Байлык кешеләрдә шуның кадәр күп булыр ки, зәкят-сәдака бирергә теләгән кешеләр: "Шушы сәдакамны кемгә бирим?" - дип аптырап борчылырлар. Ә кемдер хәерен өләшергә маташса, аңа һәркем: "Мин моңа мохтаҗ түгел", - дип әйтер.

6. Ислам динен аңлауның, мөселманнарның зәгыйфьләнүе, тәкъва кешеләрнең азаюы. Билгеле бер вакыт эчендә җәмгыятьтә ислам динен тоту йә көчәер, йә зәгыйфьләнер, ә инде кыямәт көне килеп җитәр алдыннан кешеләрнең дингә мөнәсәбәте бик зәгыйфьләнеп, шактый күп мөселман хакыйкатьтән тайпылыр, дөнья вәсвәсәләренә бирелеп, әхлаксыз, бозык кешеләрнең йогынтысына эләгер. Бу кешеләрнең тәкъвалыгы бик зәгыйфьләнәчәк, алар белән шайтан идарә итәр. Бу вакытта күпләр намус һәм әдәп, тыйнаклык һәм оялу дигән төшенчәләр турында онытыр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: "Кыямәт көне кешеләрнең иң әшәке, бозылган чакларында булыр" (ягъни җәмгыять әхлакый түбәнлеккә төшкән вакытта).

7. Ахырзаман алдыннан киенгән хатын-кызлар киемсез шикелле күренер. Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгында Әбү Һөрәйра исемле сәхабәдән китерелгән хәдистә Пәйгамбәребез (с.г.в.) шундый хатын-кызлар турында болай ди: "Алар киенгән хәлдә киенмәгән шикелле булырлар (аңлатма: йә бик кыска, йә үтә күренмле), йөргәндә исә алар йөрешләре белән ирләрне кызыктырырлар, ә чәчләре дөянең өркәченә охшаш булыр". Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтүе буенча, алар җәннәттән бик ерак булырлар (хатын-кызларның гаурәтләре, ягъни тәннәренең капланырга тиешле өлеше турында "Нур" сүрәсенең 31 нче аятендә әйтелә).

("Ислам дине нигезләре"ннән. Дәвамы бар)

Өч капчык

(Тырышлык, җаваплылык хисе һәм тормышыбызның асыл-максаты турында мәгънәле кыйсса)

Бер патша өч кешегә шундый эш куша: "Һәрберегез капчык алып, минем бакчама керегез дә, шунда уңган яшелчәләрдән һәм җиләк-җимешләрдән нәрсә бар – капчыкка җыегыз. Соңыннан амбар саклаучыга тапшырырсыз", – ди. Тегеләр кушканны үтәргә дип шактый зур бакчага кереп китәләр. Берсе, өстенә йөкләнгән вазыйфасына бик җаваплы карап, капчыгын бакчада җитешкән нигъмәтләр белән тутыра; икенчесе, яртылаш кына тутырганнан соң: "Әй, ярамаган тагы!" – диеп, капчыкның икенче өлешенә тиз генә чүп-чар атып "эшен бетерә"; өченчесе исә, бөтенләй эшлисе килмичә: "Патша амбарга барып барыбер карап-тикшереп йөрмәс, нәрсәгә азапланып вакыт үткәрим?" – дип, капчыгын тулысынча таш һәм чүп-чар белән тутыра да бәйләп куя.

Бераздан бу кешеләр капчыкларын амбарга тапшыра. Кайтып китәргә дип бакчадан чыгып барганда, аларны кинәт тоткарлыйлар һәм әйтәләр:

- Патшабыз сезне бер айга зинданга ябарга әмер бирде. Шулвакыт дәвамында сез капчыкларыгызга җыйган азык белән тукланырга тиеш буласыз!

Патша боерганны намус белән башкарган кеше шунда: "Әлхәмдүлилләһ, ярый әле, тырышып, бер ай тукланырлык ризык тупладым", – дип сөенә. Капчыгын яртылаш кына тутырганы: "Их, нигә патша кушканны җиренә җиткереп үтәмәдем икән?" – дип үкенә, ә өченчесе... бик хафаланып, хәтта тетрәнеп кайгыга төшә.

Менә бу дөньяда да бөек Патшабыз Аллаһы Тәгалә һәркемгә савап җыяр өчен "капчык" тапшыра, кешеләр исә, нәкъ югарыда бәян ителгәнчә, өч төркемгә бүленәләр. Әмма нәтиҗәсе – фәкать үзләренә ирешәчәк...

Ришат КУРАМШИН әзерләде.

Намаз вакытлары

Милади Декабрь	Көн исеме	Рабигуль-ахир, җөмәдәл-әүвәл	Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа	Таң беленә Чаллы	Таң беленә Казан	Мәчетләрдә укыла Уфа	Мәчетләрдә укыла Чаллы	Мәчетләрдә укыла Казан	Кояш чыга Уфа	Кояш чыга Чаллы	Кояш чыга Казан	Зәвәл Уфа	Зәвәл Чаллы	Зәвәл Казан	Өйлә Уфа	Өйлә Чаллы	Өйлә Казан	Икенде Уфа	Икенде Чаллы	Икенде Казан	Ахшам Уфа	Ахшам Чаллы	Ахшам Казан	Ястү Уфа	Ястү Чаллы	Ястү Казан
1	Як	4	07.01	05:17	05:31	07.16	06:04	06:17	09.09	07:34	07:47	13.06	11:19	11:32	13.30	12.00	12.00	15:40	13:15	13:28	16.59	15:03	15:16	18.46	16:58	17:11
2	Дш	5	07.02	05:19	05:32	07.17	06:06	06:19	09.11	07:36	07:49	13.07	11:19	11:32	13.30	12.00	12.00	15:39	13:14	13:27	16.59	15:02	15:15	18.45	16:57	17:10
3	Сш	6	07.04	05:20	05:33	07.18	06:07	06:21	09.12	07:37	07:51	13.07	11:20	11:33	13.30	12.00	12.00	15:39	13:13	13:26	16.58	15:01	15:14	18.44	16:57	17:10
4	Чш	7	07.05	05:21	05:34	07.19	06:09	06:22	09.14	07:39	07:52	13.08	11:20	11:33	13.30	12.00	12.00	15:38	13:13	13:25	16.57	15:01	15:13	18.44	16:56	17:09
5	Пж	8	07.06	05:22	05:35	07.20	06:10	06:24	09.15	07:40	07:54	13.08	11:20	11:33	13.30	12.00	12.00	15:38	13:12	13:25	16.57	15:00	15:13	18.44	16:56	17:09
6	Жм	9	07.07	05:23	05:37	07.22	06:12	06:25	09.16	07:42	07:55	13.08	11:21	11:34	13.30	12.00	12.00	15:37	13:12	13:24	16.56	14:59	15:12	18.43	16:55	17:08
7	Шм	10	07.08	05:25	05:38	07.23	06:13	06:27	09.18	07:43	07:57	13.09	11:21	11:34	13.30	12.00	12.00	15:37	13:11	13:24	16.55	14:59	15:12	18.43	16:55	17:08
8	Як	11	07.09	05:26	05:39	07.24	06:15	06:28	09.19	07:45	07:58	13.09	11:22	11:35	13.30	12.00	12.00	15:37	13:11	13:24	16.55	14:58	15:11	18.43	16:55	17:08
9	Дш	12	07.10	05:27	05:40	07.25	06:16	06:29	09.20	07:46	07:59	13.10	11:22	11:35	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.55	14:58	15:11	18.43	16:55	17:08
10	Сш	13	07.11	05:28	05:41	07.26	06:17	06:31	09.22	07:47	08:01	13.10	11:22	11:36	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.55	14:57	15:10	18.42	16:55	17:08
11	Чш	14	07.12	05:29	05:42	07.27	06:18	06:32	09.23	07:48	08:02	13.11	11:23	11:36	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.55	14:57	15:10	18.42	16:55	17:08
12	Пж	15	07.13	05:30	05:43	07.28	06:20	06:33	09.24	07:50	08:03	13.11	11:23	11:36	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.54	14:57	15:10	18.42	16:55	17:08
13	Жм	16	07.14	05:31	05:44	07.28	06:21	06:34	09.25	07:51	08:04	13.12	11:24	11:37	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.54	14:57	15:10	18.42	16:55	17:08
14	Шм	17	07.15	05:31	05:45	07.29	06:22	06:35	09.26	07:52	08:05	13.12	11:24	11:37	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.54	14:57	15:10	18.42	16:55	17:08
15	Як	18	07.16	05:32	05:45	07.30	06:23	06:36	09.27	07:53	08:06	13.13	11:25	11:38	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.54	14:57	15:10	18.42	16:55	17:08
16	Дш	19	07.17	05:33	05:46	07.31	06:24	06:37	09.28	07:54	08:07	13.13	11:25	11:38	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.54	14:57	15:10	18.43	16:55	17:08
17	Сш	20	07.17	05:34	05:47	07.32	06:24	06:38	09.28	07:54	08:08	13.14	11:26	11:39	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.55	14:57	15:10	18.43	16:55	17:08
18	Чш	21	07.18	05:35	05:48	07.32	06:25	06:39	09.29	07:55	08:09	13.14	11:26	11:39	13.30	12.00	12.00	15:37	13:10	13:23	16.5	14:57	15:10	18.43	16:56	17:09
19	Пж	22	07.19	05:35	05:48	07.33	06:26	06:39	09.30	07:56	08:09	13.15	11:27	11:40	13.30	12.00	12.00	15:38	13:11	13:23	16.55	14:57	15:10	18.43	16:56	17:09
20	Жм	23	07.20	05:36	05:49	07.33	06:27	06:40	09.30	07:57	08:10	13.15	11:27	11:40	13.30	12.00	12.00	15:38	13:11	13:24	16.56	14:58	15:11	18.44	16:56	17:09
21	Шм	24	07.20	05:36	05:50	07.34	06:27	06:41	09.31	07:57	08:11	13.15	11:28	11:41	13.30	12.00	12.00	15:39	13:11	13:24	16.56	14:58	15:11	18.44	16:57	17:10
22	Як	25	07.20	05:37	05:50	07.34	06:28	06:41	09.32	07:58	08:11	13.16	11:28	11:41	13.30	12.00	12.00	15:39	13:12	13:25	16.57	14:59	15:12	18.45	16:57	17:10
23	Дш	26	07.21	05:37	05:51	07.35	06:28	06:42	09.32	07:58	08:12	13.16	11:29	11:42	13.30	12.00	12.00	15:39	13:12	13:25	16.57	14:59	15:12	18.45	16:58	17:11
24	Сш	27	07.21	05:38	05:51	07.35	06:29	06:42	09.32	07:59	08:12	13.17	11:29	11:42	13.30	12.00	12.00	15:40	13:13	13:26	16.58	15:00	15:13	18.46	16:58	17:11
25	Чш	28	07.22	05:38	05:51	07.35	06:29	06:42	09.33	07:59	08:12	13.17	11:30	11:43	13.30	12.00	12.00	15:41	13:14	13:27	15.58	15:01	15:13	18.46	16:59	17:12
26	Пж	29	07.22	05:39	05:52	07.36	06:29	06:43	09.33	07:59	08:13	13.18	11:30	11:43	13.30	12.00	12.00	15:41	13:14	13:27	16.59	15:01	15:14	18.47	17:00	17:13
27	Жм	1	07.22	05:39	05:52	07.36	06:29	06:43	09.33	07:59	08:13	13.18	11:31	11:44	13.30	12.00	12.00	15:42	13:15	13:28	17.00	15:02	15:15	18.48	17:00	17:13
28	Шм	2	07.23	05:39	05:52	07.36	06:30	06:43	09.33	08:00	08:13	13.19	11:31	11:44	13.30	12.00	12.00	15:43	13:16	13:29	17.01	15:03	15:16	18.49	17:01	17:14
29	Як	3	07.23	05:39	05:52	07.36	06:30	06:43	09.33	08:00	08:13	13.19	11:32	11:45	13.30	12.00	12.00	15:44	13:17	13:30	17.02	15:04	15:17	18.49	17:02	17:15
30	Дш	4	07.23	05:39	05:53	07.36	06:30	06:43	09.33	08:00	08:13	13.20	11:32	11:45	13.30	12.00	12.00	15:44	13:18	13:31	17.03	15:05	15:18	18.50	17:03	17:16
31	Сш	5	07.23	05:39	05:53	07.36	06:29	06:43	09.33	07:59	08:13	13.20	11:33	11:46	13.30	12.00	12.00	15:45	13:19	13:32	17.04	15:06	15:19	18.51	17:04	17:17

Балалар өчен

Көзге урман

Урман алтын төскә керә,
Әкияткә әверелә.
Яфраклар әкренләп төшә,
Әйләнә һәм бөтерелә.
Ел фасыллары бик төрле,
Көзнең була төрле көне.
Аңлы балам, син күзәтче,
Бу бит Аллаһның хикмәте!
Яфрак була икән саплы,
Һәм дә утырма яфраклы.
Яфрак җәймәсе төрле булды,
Раббыбыз шулай кылды!
Безнең гүзәл ягыбызда
Үсә төрле агачлар да:
Каен, миләш, нараты да,
Юкә, имән, усагы да!
Яфраклар коела, төшә.
Һәммәсен бит Аллаһ белә!
Һәммәсен дә Аллаһ күрә,
Хәдисләрдә китерелә.

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.

Тәмле булсын!

Җимешле икмәк

Чаллының "Хәят" мөслимәләр җәмгыятендә булган очрашуда мөслимәләрнең байтагы чүпрәсез ипи пешерү серенә өйрәнгән иде. Мәрьям ханымның чүпрәсез ипи пешерү рецептын газета укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.

Җиләк-җимешле ипи пешерү өчен: төше һәм кабыгы алынган 450 г алма, 350 г он, 150 мл су, 100 г күрәгә, 100 г инжир, 100 г йөзем, 100 г әстерхан чикләвеге, 50 г каражимеш, 10 г көпшәкләндергеч, 2 аш кашыгы сыек май, 1 чәй кашыгы корица, 1 лимон кирәк.

1. Онны иләп, корица һәм көпшәкләндергеч кушарга.

2. Күрәгә, йөзем, каржимешне юып киптергәч, кискәләргә, чикләвекне вакларга, алманы вак кисәкләргә турарга һәм, кабыгыннан чистартылган лимон согы кушып, аларның барысын бергә болгатырга.

3. Су һәм май өстәргә, аз-азлап онны кушарга, кул белән камыр изәргә.

4. Ипи пешерергә дигән форманы сыек май белән майларга, әзер массаны шунда салып, кул белән тигезләргә.

5. 200 градуска тиклем җылытылган духовкада 50-60 минут тирәсе пешерергә.

Пешкәч, әзер икмәкне формадан чыгарырга һәм суытырга кирәк.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР
Баш мөхәррир
Муллагалиева А. Г.
Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45
* * *
Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы: 1500
Индексы 54149
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан саклаңыздар дип ышанабыз.

* * *
Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир, типография һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72
Басарга кул куелды:
график буенча 14 ноябрь 16 сәг.
фактта 14 ноябрь 16 сәг.
Бәясе ирекле